Белемебезне

тикшерик ■

**Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урамда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:**

**- Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, - дигән**

Өч кыз







**Икенче елны Аю белән Бабай бодай чәчкәннәр. Быел инде Бабайдан алдатмам дип уйлаган Аю.**
**- Мин быел тамырын алам, ә син сабагын ал! – дигән ул Бабайга.**
**Бабай бодайны урып алган, ә Аюга камылы калган.**

**Аю белән Бабай.**
**(Татар халык әкияте)**






**Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:**

**-Каз, мин сине ашыйм, -- дигән.**
**Каз боегып калган.**
**-Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит, - дигән Каз.**
**-Әйдә, бие, - дигән Төлке. – Ашарга өлгерермен әле.**

**Төлке белән Каз**
**(Татар халык әкияте)**





**Торна кунакка килгән. Төлке ботка пешереп сай тәлинкәгә салып куйган да Торнаны кыстый икән:**

**- Аша, дустым, аша, иркәм! Үзем пешердем, - дигән.**

- **Торна белән Төлке**

**(Татар халык әкияте)**





**Ул ура башлагач ук, аның янына бер Аю килгән. Ул Аюның аягына шырпы кадалган икән, ди.**

- Аю белән Хатын

(Татар халык әкияте)





**Бервакыт Үрдәк Каргага, үзен күрсәтәсе килеп:**
**-Мин диңгездә йөзәм, һавада очам, җирдә йөгерәм, - дигән.**
**Карга:**
**-Диңгездә чуртан кебек йөзә беләсеңме? Һавада бөркет кебек оча, җирдә болан кебек йөгерә аласыңмы? – дигән моңа.**

Үрдәк белән Карга ●





**Әүвәлге заманда булган, ди, бик ялкау ике Кеше. Болар бер тапкыр барганнар, ди, урманга. Ул урманда бик тәмле җимешләр бирә торган алма агачы үскән, ди. Болар, бара торгач, шул алма агачын күргәннәр. Олырагы әйткән, ди:**

**-Әйдә, без бу алма агачын селкетик тә алмасын коеп ашыйк, - дигән. Кечерәге әйткән:**

**-Иренмичә аны селкеткәнче, әйдә, ичмаса, астына кереп ятыйк, - дигән.**

**Ике ялкау**
**(Татар халык әкияте)**









Туган авыл

**Тау башында салынгандыр безнең авыл.**
**Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.**
**Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,**
**Шуңар күрә сөям җаным – тәнем белән…**

Мөхәммәтгариф улы Габдулла Тукаев  1886 елның 26 апрелендә элекке  Казан  губернасы Мәңгәр волосте(Арча районы) Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә.



*






Мөхәммәтгариф – Габдулланың атасы

Мәмдүдә - Габдулланың анасы

Сабыйга дүрт ай тулганда әтисе, ә дүрт яшьтә әнисе үлеп китә. Дөм ятим калган бала авылдан авылга, гаиләдән гаиләгә, кулдан кулга күчеп йөри.



***Үлем түшәгендә ятканда да Г. Тукай үзенең чын мәгънәсендә шагыйрь һәм үз халкының патриоты икәнлеген исбат итте. Соңгы минутларда да ул халкы өчен җитәрлек эш башкара алмавына көенә.***



**1913 ел, 1 апрель (соңгы фоторәсеме)**

*2 нче апрельдә бөек шагыйребезнең гомере өзелә.*

*1913 елның сүрән, болытлы 4 апрель көне. Клячкин больницасы янына меңләгән кеше шагыйребезне озатырга килгән. Халык агымы, шагыйрьнең соңгы юлын кыскарта барып, һаман алга таба шуыша. Ниһаять, Яңа бистә. Зират. Капкадан кергәч еракта түгел яңа кабер мәңгелек фатирчысын көтеп тора...*

